Иң матур көн
*Нәниләр өчен шигырьләр*
*Рәссамы Юлия Щетинкина*
Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

Хәерле иртә

Кояшның алтын нурлары
Тәрәзгә чиртә.
Уята татлы йокыдан:
— Хәерле иртә!

Чемердәтеп тәнне
Салкын
Таң җиле исә.
Ул да гүя тели безгә
Хәерле иртә.

Безне яңа эшләр белән
Яңа көн көтә.
Сәлам сиңа, өр-яңа көн,
Хәерле иртә!

Хәерле иртә

Йокысыннан тора кояш
Елмаеп-көлеп кенә.
Болыт арасына да ул
Елмаеп килеп керә.

Уятканда да уята
Нурларын сибеп кенә.
Һәй үстерә әни кебек
Иркәләп, сөеп кенә.

Шушы кояштай тормышның
Кадерен белеп кенә,
Яшәсен иде бар кеше
Елмаеп-көлеп кенә.

Кояшны алыгыз

Кояш төшкән
Йөзенә,
Йокы бирми
Күзенә.

Елый шуңа
Нәни кыз,
Кояшны, ди,
Алыгыз.

Кашкарый

Сентябрьдә чәчәк аткан,
Күз димәгән кашкарый.
Җылыт әле, дигән сыман,
Үзе кояшка карый.

Әни булдым

Мин — әниемнең кызы.
Минем кызым — курчагым.
Ашаттым да, эчердем дә,
Ни эшлим инде тагын?

Ә ул һаман көйсезләнә,
Йокламый һич кенә дә.
Әйткәнне дә аңламый шул,
Ичмасам, кечкенә лә.

Аның урынында булсам,
Йоклар идем мин күптән.
Тагын азрак көйсезләнсә,
Үзем үк йоклап китәм.

Яңгыр

— Яңгыр, нигә явасың,
Чәчләремә тамасың?
Көне буе яварга
Суны каян табасың?

Корыда яуган яңгыр

Иркен сулап куялар да,
Игеннәр: «Рәхмәт! — диләр. —
Сусап-кибеп беткән идек,
Безгә бик рәхәт!» — диләр.

Чәчәкләр дә, агачлар да
Рәхмәт әйтәләр аңа.

Яңгыр ява! Яуган өчен
Яңгырга рәхмәт ява!

## Иртән

Кикрикүк иртән тора,
Һава ярып кычкыра:
— Торды инде кошлар,— ди,—
Уяныгыз, дуслар,— ди.

Ашыгырга куша ул
Балалар бакчасына.
Анда тәмле әйберләр
Пешкән, ди, барчасына.

Әгәр соңга калсагыз,
Тәмле әйбер бетәр, ди,
Сездән алдан барыр да,
Песи алып китәр, ди.

## Безнең бакчабыз

Ямь-яшел бакчада,
Чын бакча түгел тик,—
Ул ике катлы өй.
Салганнар безгә дип.

Эче дә, тышы да
Матур бик, чиста бик.
Шул өйне без инде
Йөртәбез «Бакча» дип.

Бик матур бакча шул —
Балалар бакчасы.

## Пескәем

Бар кечкенә пескәем,
Бик акыллы дускаем.
Ап-ак йонлач күлмәге...
Бизи безнең бүлмәне.

Күзләре ялт-йолт итә,
Мыегы җиргә җитә.

Үзен бик яратам мин,
Аннан алда ятам мин.

Тик ул бик иртә тора,
Битен юып утыра.
«Мияу, мияу, мияу! — ди. —
Мин бик күптән уяу!» — ди.

## Курчаклар

Бар бик күп курчаклар.
Аларны без саклап,
Кадерләп йөртәбез,
Битләрен сөртәбез,
Буялса-нитсәләр,
Мунчага кертәбез.

Бәрмибез, атмыйбыз,
Ватмыйбыз — саклыйбыз.

Бик матур курчаклар,
Акыллы курчаклар.
Сөйкемле курчаклар!

Күтәреп, сикертеп,
Иркәләп чөябез,
Сөябез кочаклап.

## Йокла инде, курчагым

Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле,
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле!

Аргансың инде, җаным,
Йокла, минем матурым,
Мин дә синең яныңа
Ял итәргә ятармын.

## Минем бакчам

Иркен дә һәм матур да
Безнең туган илебез,
Урманга бай, суга бай
Гөлбакчалы җиребез.

Мин дә бакча үстерәм
Өебезнең түрендә,
Иптәшләрем киләләр
Бакчабызны күрергә.

Эштән кайткач, әнием
Ял итә шунда кереп,
Ул куана, алсу чәчәк
Аткан гөлемне күреп.

Җыр

Һәркемнең бар
Үз җыры.
Җырлый кое
Чыгыры.

Көянтә дә,
Чиләк тә.
Кошлар җырлый
Тирәктә.

Үз җыры бар
Җилнең дә.
Үз җырым бар
Минем дә.

Нинди җырмы?
Ул җырмы —
Су ташучы
Кыз җыры.

Туп

Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште, дип.
— Чү, Әминә, елама,
Туп батмый ул елгада.

Әйтсәм әйтим

Аптырашта калдым бераз
Аюларны күрүгә.

Җәйге кызу көндә ничек
Мөмкин туннан йөрергә?

Әйтсәм әйтим, шуны да бу
Белми икән димәссез,
Салып куярлар иде дә,
Туннары шул төймәсез.

## Куян гына булса да

Каюм, батыр
Булса да,
Ялгыз йөрми
Урманга.
Курка аю
Чыгудан,
Бүрегә
Юлыгудан.

Куян куркак,
Диләр дә,
Курыкмый бер
Нидән дә.
Шул урманда
Тора бит,
Үзе куян
Гына бит.

## Буталчык шигырь

Бөркет яши кетәктә,
Чеән яши келәттә.

Куян — агач башында,
Бүре — кыя ташында.

Тычкан улый урманда,
Тавык бар чытырманда.

Тиен качкан камышка...
Юк ла, шагыйрь ялгышкан.

Урыннарын үзгәртеп,
Укып бирче төзәтеп!

## Урманда

«Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән?»

Марс килгән урманга
Кура җиләк җыярга.
Җыйсын әле күп итеп,
Какка җитәрлек итеп.

«Җиләк җыям, как коям —
Әбиемә бүләк»,— дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
«Улым җыйган җиләк»,— дип.

## Бәти

Бар белгәне «Бә».
— Б-ә дә б-ә,— ди ул.
— Бу ни, дисәгез,—
Безнең бәти ул!

## У хәрефе

Бүреләр тиз әйтеп бирер,
Бу хәрефне сорасаң.
Үзең дә тиз өйрәнерсең,
Бүре булып уласаң.

Төне буе бүре улый —
У-у-у да у-у-у!
Бүреләр әлифбасында
Бердәнбер хәрефтер бу.

## Маэмаем

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...

## Аучы мәче

Ауга чыккан мәче,
Йөри бакча буйлап,
Тырнагына тычкан
Каптырырга уйлап.

Чыксын гына тычкан,
Ташланырга әзер.
Назлы песи түгел,
Тәбе бит ул хәзер.

## Безнең сыер

— Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә мөгери?
— Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер,— ди.

— Ашап туйгач, ник сыер
Сузып-сузып «Му-у» ди ул?
— Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! — ди ул.

## Алма

Бакчабызда үсә алма,
Ул кызыл да була, ал да,
Тәме шикәр-бал гына.
Аны гел алмаска түгел,
Рөхсәт булса — ал гына.

## Адашкан

Урманнан кайта Каюм.
— Башмагың кайда, Каюм?

Беләсездер, балалар,
Урманда югалсалар,

Ул кешегә ни диләр?
Адашкан, мескен, диләр.

Ә Каюм адашмады!
Адашкан тик башмагы.

## Капкорсак

Капкорсак, капкорсак,
Ашаган күп бавырсак.

Ашаган күп тәбикмәк,
Коймак, бәлеш һәм икмәк.

Чәкчәк, сумса, кош теле
Һәм ике табак белен.

Ашаган чакта белен,
Йотып җибәргән телен.

Аңа соң тел ник кирәк?
Ашарга бир тизрәк!

## Туган тел

Туган тел — иң татлы тел,
Туган тел — иң тәмле тел.
Тәмле дип телең йотма —
Туган телне онытма!

## Рәсемнәр ясыйбыз

Бакчада барысы бар!
Тик менә юк таулар.
Елгалар, урманнар.
Зур йортлар, урамнар.
Ә кирәк булганда
Ясыйбыз урамнар.

Ямь-яшел урманнар.
Төлкеләр, куяннар...
Бик оста без аңар,
Бездә бар буяулар:
Ак, кызыл, ал, зәңгәр,
Сарылар, яшелләр...

Ясыйбыз дәфтәргә
Бик матур рәсемнәр.

## Кыш

Уянып, бүген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Әйдәгез, тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

## Оекбаш

Кыш көне салкын булса да,
Һич туңмый минем аяк.
Җылыта аны дәү әни
Бәйләп биргән йон оек.

Сарык йоны җылы була.
Бар бит тагын шунысы —
Күчкән аңа дәү әнием
Кулларының җылысы.

## Беренче кар

Йомшак кына кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

## Саф һава

Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Буран

Урамда — буран.
Мин өйдә торам.
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам.

Әй, җил выжылдый,
Буран дуылдый.
Ачулы песи
Кебек мырылдый.

Җиңдем, ди, бугай,
Дуланып шулай.
Әй, бичаракай,
Кыланма болай.

Эчтәлек

Матур көн. *Рафис Корбан* .............
Хәерле иртә. *Рафис Корбан* ............
Кояш. *Хәкимҗан Халиков* ............
Кояшны алыгыз. *Рафис Корбан* ..........
Кашкарый. *Рафис Корбан* ............
Әни булдым. *Йолдыз* ................
Яңгыр. *Вәсимә Хәйруллина* ............
Корыда яуган яңгыр. *Шәүкәт Галиев* ......
Иртән. *Дамир Гарифуллин* ............
Безнең бакчабыз. *Бари Рәхмәт* ..........
Пескәем. *Мәхмүт Хөсәен* ..............
Курчаклар. *Бари Рәхмәт* .............
Йокла инде, курчагым. *Әминә Бикчәнтәева* .
Минем бакчам. *Әминә Бикчәнтәева* .......
Җыр. *Рафис Корбан* .................
Туп. *Әминә Бикчәнтәева* .............
Әйтсәм әйтим. *Рафис Корбан* ...........
Куян гына булса да. *Рафис Корбан* ........
Буталчык шигырь. *Рафис Корбан* ........
Урманда. *Клара Булатова* ............
Бәти. *Рафис Корбан* .................
У хәрефе. *Рафис Корбан* ...............
Маэмаем. *Муса Җәлил* ................
Аучы мәче. *Рафис Корбан* ..............
Безнең сыер. *Нәкыйп Каштан* ...........
Алма. *Нури Арслан* .................
Адашкан. *Рафис Корбан* ...............
Капкорсак. *Рафис Корбан* .............
Туган тел. *Шәүкәт Галиев* ............
Рәсемнәр ясыйбыз. *Бари Рәхмәт* .........
Кыш. *Җәват Тәрҗеманов* ............
Оекбаш. *Рафис Корбан* ................
Беренче кар. *Әхмәт Ерикәй* **...........**
Саф һава. *Әминә Бикчәнтәева* ..........
Буран. *Гомәр Толымбай* ..............

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)–5
К 52
Иң матур көн: Нәниләр өчен шигырьләр.— Казан: Тат.кит.нәшр.,2005.— 47 бит.
Литературно-художественное издание для детей

*Коллектив*

**ПРЕКРАСНЫЙ ДЕНЬ**

Стихи

(на татарском языке)

Төзүче мөхәррире *Р.Х.Корбанов*. Бизәлеш мөхәррире. *Р.Г.Шәмсетдинов*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*. Корректоры *Г.Х.Сундукова*. Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.03.2005. Форматы 70г901/32. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 1,76. Шартлы буяу-оттиск 7,32. Нәшер-хисап табагы 2,76. Тиражы 5000 экз. Заказ А-147. Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19. **http:/www. tatarstan.ru/books/E-mail: tki@books.kazan.ru.** «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар
предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.
ISBN 5–298–04087–X
© Татарстан китап нәшрияты, 2005